

## *Газизов Әхәт Газиз улы.*

*Бүгенге көндә күп кешеләр өчен материаль байлыклар рухи байлыктан өстенрәк тора. Һәрбер кеше каядыр чаба, ашыга, үзенең максатына ничек тә булса ирешергә тырыша – бер сүз белән әйткәндә: дөнья артыннан куа һәм һәрвакыт аңа нидер җитми. Ләкин бер мизгелгә туктап, дөнья мәшәкатьләрен онытып торсаң, табигатьнең гүзәллегенә, күк йөзенең тынычлыгына карап хәйран каласың. Кызганычка каршы, күп кеше, бигрәк тә яшь буын, бу матурлыкны күрергә сәләтле түгел, алар "сукырлар". Аларның күзләре бар, ләкин алар күрмиләр. Ягъни, алар бу дөньяның ни кадәр гүзәл икәнен, тынычлыкның  һәм туганнарның никадәр кадерле икәнен белмиләр. Белмиләр, чөнки аларның бу бәхетне югалтып караганнары юк.. Ә бер сынык ипигә тилмерүчеләр, сугышта әтиләрен югалтып, әти дип әйтергә тилмерүче балалар рәхәт балачакны күз алларына да китерә алмаганнар. Без күргән балачак, уен- көлкене алар өчен караңгы күкле, дары исе килеп торган, ач сугыш еллары алыштырган. Шундый сугыш чоры балаларының берсе  – Әхәт абый. "Без күргән тормышны эт тә күрмәде",- дип исенә ала ул афәтле елларны.*

*"Сугыш башланганда миңа 10 яшь иде. Коточкыч хәбәрне ишетеп, әти сугышка җыена башлагач, мин әтинең аягына ябышып:  "Әти, китмә! Әти китмә",- дип үксеп- үксеп елаганымны ачык хәтерлим. Әти мине: "Улым, мин кайтам, борчылма, армиягә генә барып кайтам",- дип юатып чыгып китте. әтине һәм бертуган абыйны басуга кадәр озаттым, шул көннән башлап иң ачы еллар исемлегенә аяк бастык. Гаиләдә  5 бала калдык. Апайлар һаман нарядта йөрделәр, анда чирләп, ачка тилмереп, хәер өстәп кайта торган иделәр, шул сәбәпле апа авырып үлде.*

*Укуга килгәндә минем 1 класс белемем бар, бик матур яза идем, укытучы апа, хәтта "Карагыз, Әхәт ничек матур язган",- дип, минем язуны балаларга үрнәк итеп күрсәтте. Шул вакыттагы белемем белән әле дә газетлар укыйм, кул куям.*

*11 яшьтән балачак белән саубуллашырга туры килде. Алда бик зур бурыч: әнигә булышасы, гаилә ашатасы. Күп атларны фронтка алып киткәнлектән, атлар бик әз иде. 7-8 бабай белән гектарлы басуларны чәчеп бетерә торган идек. Атларны фронтка алып киткәндә, туганыбызны озаткан сыман, елап калдык. Шуның өстенә әле атларны бүре тота иде. Эшләгәнгә бер таяк язалар, бер уч арыш та бирмәделәр. Ел буе эшләгәнгә 1 пот арыш бирсәләр, шатланырсың.*
*Үсә төшкәч, үзем ат җигә, торма тормалый, басу сукалый башладым, әвендә арыш сугабыз,көне буе молотилка әйләндерәбез, басулардан алып кайткан арыштан келтә ясыйбыз, төн уртасында кайтабыз.Ничек шул вакытта түзгәнбездер, ничек үлмәгәнбездер инде. Бозаулар белән ташлар ташый идек , җир тормалый идек. Алар тагын бармый, сугып карыйсың, этеп карыйсың. Шулай иза чиктек. Арышны 1 уч та өйгә алып кайтып булмый, эштә вакытта бер ике бөтрек ашап та булмый иде хатта. Авылдагы бер апаны 2 кесә арыш урлаганы өчен 7 елга төрмәгә утырттылар, өйләрендә 5 бала калды, авырып, әчкә тилмереп үлеп беттеләр, җаныйларым.*
*Ашауга килгәндә, басулардан черек бәрәңгеләр җыйдык, әле анысын да җыймагыз дип куа торган иделәр, көрәкләрне сындырдылар, чиләкләрне ваттылар. Соңыннан ашка дип кычыткан, бәрәңге яфраклары, тәтем, кузгалак, какы, 1-2 бәрәңге эләксә эләккән,хәтта камыш төпләрен, әллә нишләп беткән бәрәңге ашадык. Чәй эчәргә алмагач яфраклары, кура яфраклары җыя идек. Чөгендер булса, чөгендер киптереп, конфет урынына ашыйбыз. Төне буе 3әр чиләк бәрәңге игеп, таралмаска гына әз-мәз он сибеп шуны пешерәбез. "Әле дә авырта бәрәңгене иккәннән кулда калган яралар. Авылда алмагач 4 гаиләдә генә булган вакытта, безнең бакчада да 1 төп алмагач бар иде. Үзебезнең басу да бар иде. Ул басуны кул белән казып, кул белән тырмаладык. Әни колхозда сарык караучы булып эшләде. Үзебез кысыр сыер асрадык, 4 ел суярга рөхсәт бирмәделәр. Соңыннан, сыерны килога кило арыш белән алыштырдык. Шулай ук бераз тавыкларыбыз да бар иде. Алар бәрәңге кабыгы, ат кузгалагы ашадылар. Колхозга заёмга йомырка, сөт түләргә кирәк булганлыктан, тавык асрап та, елына 1 йомырка да ашамаган вакытлар булды. Тик торганда кереп, лапас түбәсенә җәелгән саламны, колхоз хайваннарына дип алып чыгып китә торган иделәр. Бер нишләп тә булмый, нишлисең...Ул заёмның берсен түләп бетергәнче икенчесен салып та куялар. Әниләр урактан кайтканнан соң, чакыртып алып, заём түләмәгәнгә төнгә ябып куйдылар. Иртәгә чаклы аларны шунда тоттылар, туп-туры эшкә генә җибәрделәр. Ябылган хатыннар "кайтып бала гына ашатып килим",- дигән үтенечкә, заём җыючы, өстәлгә сугып "Ачка үлсен шунда балаларыгыз",- дип кычкыра торган булган.*
*Аннары мине нарядка, урман кисәргә йөртә башладылар. 2 тапкыр 6 айга Пермьга, 4 айга Лаешка, 4 айга Ашлангерга, 2 айга Гәргә мәҗбүри җибәрәләр иде. Бармасаң, төрмәгә ябабыз дип куркыталар. "Салкын землянкаларда*

*ятканда, салкын тәмам үзәккә үтә иде, кияргә кием дә җүнләп юк иде.Анда баргач та, ашарга әз-мәз ярма гына бирәләр иде, анысы җитми дә иде әле. Салкын вакытларда өйгә урманнан ботаклар җыеп яга торган булдык, алар гына да түгел, сыерның киптерелгән тизәгенә, бәрәңге сабакларына, сыердан калган саламга да калган көннәр булды. Безгә, 30-31 нче елгыларга бик күп эләкте инде. Бик начар вакыт иде, 46 градус салкында, чабатадан чыгып йөргәндә, куенга тыгылган күмәч ката иде. Катып кына үлмә инде. Өйдә ишекләргә юрганнар элә идек, тәрәзәләргә чүпрәкләр, кая өй ул бәрәнге яфрагын ягып җылынсын инде. Шул салкыннарда бозауны да, 3-4 бәтине дә өйгә алып керә идек.Катып үләләр бит алайса.*
*Бер заманны кызамык авыруы башланды. 5 бала идәндә хәйран авырып яталар, алар арасында мин дә бар. 3 туганым шул авырудан вафат булдылар, 13,7,3 яшьлек энеләрем иде. Ул вакытта больницалар юк, әниләр бала тудырырга Мәмдәлгә баралар иде. Шул вакытта ник мин дә үлмәдем икән, бу эт тормышында яшәмәс идем дип әрнеп-әрнеп бик еш елый торган идем. Авылга хәтта фронттан качкан качаклар киләләр иде, бер вакытны берүзем Гәр юлыннан кайтып барганда карда аларның штабларын да күрдем. Ул урыннан ерак түгел чишмә бар иде, шул чишмә яннарында качаклар яшәп ята торган булганнар. Шул сәбәпле авылларда караклар йөриләр. Алар сөтләрне урлап алып чыгып китәләр, тавыкларны урлыйлар. Хәтта бер вакытны көпә-көндез бәрәңге алырга басуга менеп киткәч, апайларга нарядка йөрергә ипи алырга дигән дәү генә тәкәбезне, баз өстеннән кибергә эленгән керләрне алып чыгып киткәннәр.Соңыннан, иртәгә суябыз дигән көнне әзрәк чистарсыннар дип суга казларны алып төштек, карасак, казларның 1 йоны да калмаган. Җәй буе симерткән, караган 30 казның 1 грамм йоны да калмаганга бик әрнедек ул вакытта.*
*Әниләр фронтка оекбашлар, бияләйләр бәйләп җибәрә иде, үзебезгә аякка чырнарга ертек күлмәкләр дә юк иде, ичмасам. Капчык та юк иде ул вакытта, булса, бик аякка чырнар идек тә.Чабата туза, аяклар күренеп йөри, яңаны алырга акча юк. Киез итекләр ул вакытта юк та юк инде.*
*Ачка үлүчеләр турында хәбәрләр бик еш килә иде. Шулай, бер Казан апае хәтта Ювас юлында ачка үлеп калды. Өендәге әйберләрен тапшырып, моннан бәрәңге алып китәргә килгән  булган. Шулай алыштыра -  алыштыра өйрәрендә савыт- саба да калмаган аларның киемнәр дә калмаган дип ишеткәннәр.*
*Әни сугыш бетте дигән хәбәрне җиткергәч, мин егыла- егыла әбиләргә чыгып чаптым. Ул көнне бар халыкның да шатлыгы эченә сыймады.Балалар яланаяк йөгереп йөрделәр.*
*Сугыш беткәч тә,  әтиләрне кайтармыйча урман ташыттылар әле. Шуннан бер көнне әни белән бәрәңге сатарга Казанга барганда, әти кайтып килә. Шунда күрешеп, елашканнан соң, әти, өйгә дә кайтып тормыйча, әни белән сатарга китте, мин калдым. Әнигә аз гына булса да булышыйм дип аның белән хәтта шундый ерак юлларга да чыгарга риза идем. Соңыннан инде авылга*

*солдатлар берәм – берәм кайта торган булдылар. Фәлән кайткан, тегән кайткан дигән хәбәрләр килеп кенә торды. Әти кайткач, тормыш алга китте. Нинди генә эш булмасын, ир ат көче, ир ат көче инде...Әтисе булмаган балаларны мыскыл да иттеләр, пычрак эшләр дә куштылар, аларга бик кыен иде.*
*Әти сугыш хатирәләрен еш сөйли иде. Шулай, бер вакытны безнең гаскәрләр алгарак киткәннәр дә, әти берүзе арттарак калган, караса, каршысына бер бик ярау немец солдаты килә. Ул да килә икән,  әти дә килә икән, шуннан соңгы патронын  әти аллага тапшырдык дип атып җибәргән дә, немец үлгән.*
*Сугыштан кайткач та,  әти озак яшәде. Зав ферма, бригадир булып эшләде.*
*Сугыш вакытында Германиягә кадәр барган ул.*
*Бүгенге көндә 7 бертуганымның икесе генә исән.  Кулга кул тотынышып эшләгән14 иптәшемнең инде икесе генә исән.*
*Кадерле балалар, менә шушындый заманда гына яшәсәгез иде, я раббым.Без бу заманны төштә дә күрмәгән инде, төшкә керер дип тә уйламаган. Бер туйганчы ипи ашарбыз микән дип уйлый идек. Дөньялар шушылай тыныч кына торып, рәхәт яшәсеннәр хәзерге заман балалары, я раббый, без күргәнне күрмәсеннәр.*

